КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2020 ел, 6 май г.Казань № б-906

Халыкка дәүләт сәясәте, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый һәм мәдәни үсеше турында киң мәгълүмат бирү максатларында:

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына ведомство буйсынуындагы оешмалар (мәгариф оешмаларын, сәламәтлек саклау оешмаларын, мәдәният оешмаларын кертеп) өчен, аларның юнәлешен исәпкә алып, 2020 елның беренче ярты еллыгына вакытлы матбугат басмаларына, шул исәптән «Российская газета», «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» иҗтимагый-сәяси газеталарына, «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналына, «Казан утлары» журналына язылуны оештырырга һәм язылган басмалар санын 2020 елның беренче ярты еллыгына язылган басмалар санныннан ким булмаган күләмдә тәэмин итәргә.

2. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре территориясендә 2020 елның икенче ярты еллыгына язылу кампаниясе барышын тикшерүдә тотуны тәэмин итүне;

«Российская газета» газетасы, район, шәһәр газеталары һәм республика журналлары, шул исәптән «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакцияләренә, «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» һәм «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» дәүләт учреждениеләренә вакытлы матбугат басмасын популярлаштыруга һәм аларга язылуны активлаштыруга булышлык күрсәтә торган чараларны үткәрүдә һәрьяклап ярдәм күрсәтүне.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына, «Татарстан почтасы» федераль почта элемтәсе идарәсе йөзендә «Россия почтасы» акционерлар җәмгыяте белән берлектә, 2020 елның 15 июленә кадәр:

Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары яктылыгында 2020 елның икенче ярты еллыгына язылу кампаниясе йомгаклары турындагы мәгълүматны «Ачык Татарстан» порталында урнаштырырга;

2020 елның икенче ярты еллыгына вакытлы матбугат басмаларына язылу кампаниясе йомгаклары турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына язылу кампаниясен массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртуны оештырырга.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры А.Р.Хәйруллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин